
Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ МАЙ * 2024 * КАЗАН

5



Александр АЛЁШИН



Сәяси карикатура конкурсыннан рәсемнәр





Алмаз ХӘМЗИН

ЯМАУГА – ЯМАУ

Менә тагын мин сайладым
Яңа итеп искене.
Әллә ниләр уйламагыз, –
Элек кигән ботинкама
Ямау салдым яз көне.

Күптән киямен мин аны,
Ул аякка җайлашкан.
Ташласаң да була иде, –
Күнегелгән, җылысы юк...
Билдән түбән – бер ыштан...

Ямый-ямый туеп беттем,
Тузган инде, ышкылган.
Яңасына акча җитми,
Ишек катында тора ул,
Дими бит: "Алышынам!"

Моны бушка да алучы
Күренмәс, юк сораучы.
Табылмас шул, аның белән
Чыгып китеп, кире исән
Кайтучы берәр юлчы...

Бигрәк беткән икән, диеп,
Кайгырмагыз әле сез.
Ботинка турында язу
Бер җай гына икәнен бит
Барыгыз да сизәсез.

Тагын кайтам, аптырап, шул
Ботинкама әйләнеп.
Нәрсә языйм соң?! Башка сүз
Юк, табалмыймын. Хәйләләп
Утырам шуңа бәйләнеп.

Яшәештә дә шундый хәл, –
Бөтен нәрсә буталган...
Үзгәртәбез, дип, сылыйбыз
Иске өстенә искене, –
Ямауга ямау һаман...





ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Кешелекнең көннән-көн ахмаклана баруы беркемгә дә сер түгел. Шуңа күрә соңгы вакытта берөзлексез ясалма интеллект турында сөйлиләр һәм аңа зур өметләр баглыйлардыр. Имештер, ул дәвалаячак та, укытычак та, һәм симфония белән романнар да иҗат итәчәк.Ә күптән түгел ясалма интеллект коррупциягә баткан зур түрәләрне дә алыштыра алачак, дигән хәбәр чыкты...

Р. НӘБИУЛЛИН

әлмәт

– **Юк, монысы инде бик шикле...** – диде Шомбай ага. **– Табигый комсызлык каршында хәтта ясалма интеллект көчсездер, дип уйлыйм...**

Хәмид ВӘЛИДИ

БАРЫП КАЙТУ...

(Быел гаилә елы)

Тормышның борма юлыннан
Ике пар узып бара.
Беренчеләр: җегет тә, кыз,
Бер сантиметр ара,
Алар – Мәхәббәткә бара!
Икенчеләр: ир белән хатын,
Ярты чакрым ара.
Боларымы? Болар, мөгаен,
Мәхәббәттән кайтып бара.
...Тормыш юлы сикәлтәле,
Кантарлана, тарая,
Мәхәббәт нурлары гына
Аны киңәйтә ала.

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

- Ирләр тавыклар кебек – өйдән ераграк китсәләр, алар беркемнеке дә түгел.
- Мин дә өлкән абзыем кебек миллиардер булырга хыялланам. Ул да хыяллана иде...
- Кешеләр синең белән сөйләшми башлагач, синең турыда сөйли башлыйлар.
- Тормыш мине күп нәрсәгә өйрәтергә тырышты, ләкин мин дәресләрне калдырдым.
- Әгәр дә син икейөзле икәнсең, аларның берсе белән булса да кешеләргә ошарга тырыш.
- Җүләрнең дә акыл йоктыруы мөмкин, ләкин иммунитет һәрчак сакта.
- Пессимист көзгедә – карикатура, ә оптимист дусларча шарж күрә.

(Тормыш белгечләре мәҗлесендә язып алынды.)

Валентин ДУБИНИН



Игорь КИЙКО



Ике аяклы дроннар

Безнең ару-талу белмәс элекке көнбатыш партнёрларыбыз тырышлыгы белән тел байлыгыбыз акылга сыймаслык сүзләр белән баеды. Мисал өчен, "гуманитар бомбардировка" яисә "чамалы терроризм" кебек төшенчәләрнең мәгънәсен аңлау үтә кыен. Ә күптән түгел генә тагын бер яңа сүз барлыкка килде – ул да булса "биодрон". Бу – теракт йә диверсия ясау өчен ялланган кешеләр. Әйе, бүген яман эш башкаручыларны йөк ташучы йә өй караучы кебек ялларга була. Төшенчә буларак ул бик катлаулы түгел, тик аның артында гаҗәеп күренеш тора. Кемдер моңа акча өчен, кемдер хисләренә бирелеп, ә кемдер гади ахмаклыкка күрә бара. Мондый "эш" гадәттә бер тапкыр гына башкарыла, ә аның алдагы язмышы "эш бирүчеләрне" әллә ни борчымый.

Ике аяклы "беспилотник"ларның активлыгы көчәю махсус хәрби операция башлануга туры килде. Ул чакта күршедәге безгә карата дошман булган дәүләттәге "хуҗа"лар Россиядәге хәрби комиссариатларга ут төртү аларны җиңүгә китерер дип уйлаганнар. Северодвинск шәһәрендә, мәсәлән, Төньяк Арктика федераль университетының 76 яшьлек профессоры җирле военкоматка һөҗүм итәргә маташкан. Билгесез әһелләр өлкән яшьтәге галимне ул бинада... илне сатучылар оясы урнашкан дип ышандырганнар. Әмма карт ут төртүченең соңгы мизгелдә куллары калтыранганмы – анысы билгесез, ләкин ул каршыдагы газонны гына яндыра алган.

Хабаровскидагы комиссариат та диверсант кулыннан зыян күрә язган. Бу юлы атакага 65 яшьлек пенсионер хатын ташланган. Ул "Молотов коктейле" ярдәмендә максатына ирешергә булган, әмма аның шәһәр географиясен начар белүе сәбәпле, һөҗүмне үзенә мобилизациягә бернинди катнашы булмаган шәһәрнең Үзәк китапханәсе кабул иткән.

Президент сайлаулары чоры кураторларны ысулларын һәм коралларын алыштырырга мәҗбүр иткән. Биодроннарны бу юлы яшел буяу белән тәэмин иткәннәр. Монысы иң шау-шу чыгарган очрак – бу юлы да профессор, тик бу юлы Екатеринбургтагы федераль университетныкы. Ханым башта мошенникларга 15 миллион сум биргән, ә аннан соң аны, акчаны кире кайтарырга вәгъдә итеп, сайлау участокларының берсендә сайлау урнасына яшел буяу салырга мәҗбүр иткәннәр. Тик полицейский һәм комиссия әгъзаларының уяулыгы профессор ханымга максатын тормышка ашырырга бирмәгән – аны алдан ук эләктереп алганнар. Өстәвенә, яшел буяуның һөҗүм чарасының иң яхшысы түгеллеге ачыкланган. Халыкның ихтыяр белдерүе бозылган бюллетеньнәрдә дә яхшы укыла икән.

Татарстан да ике аяклы дроннар турында бик шәп белә. Чаллыда 20 яшьлек Булат Ибраһимов шул ук билгесез кураторлар күрсәтмәсе буенча, стратегик яктан әһәмиятле объектларны яндырырга йөкләмә алган. Бәясе мулдан булган – 4 тән 10 миллион сумга кадәр. Тик шома егет үзен сакларга булган һәм башкаручылар итеп акыл ягыннан ныгып җитмәгән өч яшүсмерне яллаган. "Ялчылар" башта челтәрле элемтә вышкасын яндырганнар, ә аннары тимер юл светофорының реле шкафына ут төрткәннәр. Әмма аларның берсе дә миллионер була алмаган. Үсмерләр 42 мең сум акчага һәм суд эскәмиясендәге урыннарга гына лаек булганнар.

Хәзерге терроризм – киң колачлы һәм ысулларга бай. Ул кара сакаллы ялгыз фанатиклар түгел, ә матди яктан зур мөмкинлекләре булган күп аяклы җанвар – андыйларны караңгы почмакта кысып кына куркытып булмый. Һәм аларны ничек кенә атама – идея өчен көрәшчеләр дипме, шәһәр партизаннары дипме – аларның максатлары бер: акылларга чуалыш һәм күңелләргә курку хисе кертү. Ә ул җанварга каршы торучылар – дәүләт һәм махсус органнар, һәм,әлбәттә, яхшылыкка ышанычын һәм хәтта юмор хисен югалтмый торган кешеләребез. Көлке дә корал бит ул. Мәсәлән, менә мондый мәзәккә ничек елмаймыйсың ди: "Террорчыны гафу итәргә буламы? – Аларны күкләр генә гафу итә ала, ә безнең максат – ул очрашуны оештыру".

Людмила САФИУЛЛИНА



Александр АЛЁШИН





• • •

Сөйгән кызымның телефонына хәбәр җибәрдем:

– Хәерле төннәр!

Җавап булып мондый СМС килде:

– Ә нигә шундый тәкәббер тон белән?

• • •

– Карагыз әле, ир кеше, сез өйләнгәнме?

– Хәзерме, әллә гомумәнме?

• • •

Сәрхушлектән дәвалау хастаханәсенең төп ялгышлыгы шунда: палаталар өч кешелек булуда.

• • •

– Ә ул сиңа үзенең элеккеге мөнәсәбәтләрен сөйләдеме?

– Юк.

– Вәт сарык! Ә син аңа?

– Юк.

– Акылың бар икән әле!

• • •

Элек киноларда төшереп бетерелмәгән актёрлар бар иде. Үзләре шәп актёрлар, ничектер шулай килеп чыккан инде. Хәзер төшерелмәгәннәр – түрәләр чутлана. Шулар арасында утыртылып бетмәгәннәр дә байтак.

• • •

Әгәр Африка елгасы ярларында сезгә шашкан буйвол һөҗүм итә икән, суга ташланыгыз. Ул сезнең арттан суга кермәс – крокодилдан куркыр.

• • •

Аңлыйм, миңа бюджетны бүләргә ышанып тапшырмаслар. Әмма бюджеттан пычкы чүбе хәтлесе калса да, мин риза, ул бит бик керемле шөгыль.

• • •

Туптан өйрәнегез: аңа никадәр ныграк типсәң, ул шулкадәр биегрәккә күтәрелә.

• • •

Берничек тә мәгънә таба алмыйм, әгәр депутат – халык хезмәтчесе икән, аның нинди кагылгысызлык хокукы булсын?

• • •

Мошенниклардан хат килде. Ай саен безгә акча бир, ә без сиңа аны 65 яшең тулгач кайтара башларбыз, диләр. Моннан да ныграк ахмаклыкны белмим.



Абау!

КИРӘКЛЕ КЕШЕ КУЛЫНА

Казанда бер бурычлы кеше суд приставы З. Ильвинага 500 мең сумлык бурычын ябу өчен, үзенең машинасын сату үтенече белән мөрәҗәгать иткән. Тегесе автомобильгә арест салган. Сатуларда реализацияләнгән машина кирәкле кеше кулына – пристав кызның егетенә эләккән, ә акча Суд приставлары федераль хезмәте счётына күчерелмәгән. Бурычының ябылуын бик озак көткәннән соң, сабырлыгын җуйган гражданин тиешле урынга мөрәҗәгать иткән.

«ЦИФРЛЫ ИКЪТИСАД» ӨЧЕН

Иннополисның «МР ЧЕК» компаниясе "Цифрлы икътисад" проектын тормышка ашыру өчен, 8,5 миллион сумлык грант откан. Компания бу эшне бик үзенчәлекле итеп башкарган – алган йөкләмәләр үтәлмичә калган, ә 7 миллион сум эзсез югалган. Өстәвенә, җиде хезмәткәр өч айлык хезмәт хакыннан колак каккан. Ә фирма хуҗасы исә "авыр вакытларны" чит илдә уздырырга булган, ләкин нәтиҗәдә, туган якларына кайткан. Хәзер аңа "Цифрлы икътисад" өчен тикшерүчеләр каршында җавап тотарга туры киләчәк.

ХӘВЕФЛЕ ТАБЫШ

Күп балалы бер хатын мәктәп чатлары ярдәмендә 29 кешене өткән. Башта ул төрле компанияләрнең сертификатларын ярты бәягә тараткан. Беренче клиентлар сертификатларны алганнар һәм бик риза булып калганнар. Ләкин соңрак заказлар тоткарлану белән үтәлә башлаган, ә аннары бөтенләй килми башлаган. Ә хатын акчаны ала барган. Җиңел табышның тәмен тоеп, ул арзан бәягә лагерь юлламалары тәкъдим итә башлаган. Нәтиҗәдә, шома ханым өч миллион сум үзләштергән. Хәзер аны суд карары көтә.

ЯЛГАН ФИЗРУК

Татарстан мәгариф министрлыгы мәктәпләрнең берсендә ялган физрук эшләвен ачыклаган. Дипломы буенча ул Казан олимпиада резервы училищесында белем алган. Ләкин анда мондый студент турында ишеткәннәре дә юк икән, өстәвенә, дипломы да иске үрнәк буенча булып чыккан. Педагогика кадрлары әзерләү сайтларын тикшергәннән соң, чиновниклар күбесенчә документларның укытмыйча гына сатылганын ачыклаганнар. Шәхси папкаларны барлаганнан соң республика мәктәпләренең 80 процентында ялган квалификацияле педагоглар эшләве билгеле булган.

Максим СМАГИН



Вячеслав ШИЛОВ



Александр МОЛОТКОВ

Гаилә бәхете

Кичен ашап-эчкәннән соң – җайлы йомшак кәнәфи һәм телевизор. Хатыны савыт-сабалар юганнан соң икенче кәнәфигә кучә. Тормыш мәшәкатьләреннән арынып, рәхәтлеккә чума, үзенә чираттагы кофтасын бәйли башлый.

"Шулхәтле рәхәт икән шул үзеңнең йортың, гаиләң булуы, дип куанып уйлап куйды ире. Әти-әнисенә комачауламый гына, балалар бүлмәсендә дөньясын онытып, уенчыклары белән улы уйнап утыра.

Телевизор экранында ниндидер курорттагы реклама барлыкка килә: комлы пляж, зәңгәр диңгез, кояш һәм зәп-зәңгәр күзле озын төз аяклы блондин кыз. Менә ул кояш нурларына уралып, диңгез кырыена килә, иркә дулкыннарны ерып, диңгезгә керә һәм үзенең сокландыргыч күкрәгенә су коя.

"Менә кайда ул дөнья рәхәте. Менә ул тормыш, яшәү! – дигән фикер куерып ала иренең күңелендә. – "Яшәп тә карыйлар инде кешеләр, үзләреннән бернәрсәне чикләмиләр: диңгез, кояш, вино, шашлык, кичен танцы һәм яңа мәхәббәт".

– Нәрсә карыйсың син анда, хыялый? – дип гөлдерәп алды хатыны. – Синең буш акча янчыгың һәм арык гәүдәң белән үзебезнең бакчада гына качып ятарга була бит!

– Ә нәрсә булган? – Ире моның йөрәк өзгеч мыскыллы сүзләрен кире боргандай итте.

– Күрәм бит, күзләрең ничек яна башлаганын, оятсыз!

– Син уйлаган башыма да килмәгән иде әле, – дип акланган булды ире.

– Кемне алдарга телисең? Инде калтырый ук башладың бит. Менә улымны алырмын да әнигә китеп барырмын әле, туйдым, билләһи…

Ир үзен гаепле тойса да, барыбер күзенең бер кырые белән экраннан аерылмады. Блондинка инде билдән суда.

– Ә аның күкрәкләре һәм арт саны силиконлы, – дип мыгырдап куйды хатыны. – Тешләре дә куелмалы, – дип өстәде.

– Нәрсәсе? – дигән булды ире, бернәрсә аңламагандай.

– Әле җүләргә дә салышасыңмы? Бүген бала бүлмәсендә – идәндә йокларсың, менә шунда фантазияләреңә ирек бирсәң дә ярар… – дип хөкем чыгарды хәләл җефете.

– Мин бит әллә ни начарлык кылмадым бугай, андый яза алырга, – дип акланды ире.

– Эшләгән булсаң, бусагадан да кертмәс идем… Минем каршыда шул нәрсәләрне карап ятасың, әгәр өйдә булмасам ниләр эшләр идең, юньсез?

Экранда ниндидер музей экспонатлары күрсәтә башладылар һәм бөтен буе-сыны белән Аполлон гәүдәсе калыкты.

– Кара! – диде ире хатынына.

– Карау түгел, мин, гомумән, классиканы яратмыйм. Әйдә, йоклыйбыз… – дип кырт кисте җәмәгате.

Ир шатлыгын яшермәде, сизеп тора бит, ирекле уйлары өчен ул гафу ителгән. Карават кырыена килеп яткач, уйларына бирелеп: "Нинди рәхәт гаиләң булу. Ачуланышсаң, гафу да итә беләләр… Менә шул инде ул гаилә бәхете…"



Александр ЛЕВИТИН



Вячеслав ШИЛОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ

Абау!

КҮҢЕЛСЕЗ БӘЙГЕ

БЕРНИ ИЗГЕ ТҮГЕЛ

Приморьеда яшәүче гаилә алдау белән эләгә. Аларның дачаларында эшләгән, туганнары булмаган 46 яшьлек ирне СВО зонасына барырга күндергәннәр. Китәр алдыннан аны 63 яшьлек ялган хатынга өйләндергәннәр, «хатын-кыз» исеменә банк счёты ачканнар, әмма аны үз мобиль банкына бәйләгәннәр. Ир-ат сугыш кырында башын салган, ә бу очракта тиешле 8,5 миллион күләмендәге түләүләр «тол хатынга» бирелмәгән – ир белән хатын бөтен бу сумманы үзләренә үзләштергәннәр.

КҮП ФАМИЛИЯЛЕ


Иваново өлкәсендә суд приставлары, ниһаять, явыз алиментчыны тотканнар. Баласына акча түләмәсен өчен ир-ат, эзләрен бутарга тырышып, исемен һәм фамилиясен үзгәрткән. Хәйләкәр хәйлә өч тапкыр узган, әмма чираттагы УФМСКА килүенә күп фамилияле кешене анда көткәннәр. Алиментлар буенча бурыч ярты миллион сум тәшкил иткән. Приставларга ир-ат һәр тапкыр «барысын да яңадан башларга» теләгәнен аңлаткан.

ДУСЛЫККА ТҮГЕЛ, ХЕЗМӘТКӘ


Владикавказ полициясе подполковнигы Тотрадз Бутаев өстәмә керемнәр турында уйланган. Ул погоннар кигән килеш карак булырга теләмәгән, шуңа күрә легаль бизнесны төзергә карар иткән – берничә коттедж төзергә һәм аларны арендага бирергә. Эшче көч белән генә экономияләргә исәплгән. Ул төзелешкә алты хезмәткәрне җәлеп иткән, аларга хезмәт хакын калдырган һәм турыдан-туры бурычларыннан азат иткән. Хезмәт автомобилен дә тапшырган. Финанс перспективаларына хезмәт тикшерүе комачаулаган.

БАРЫСЫ ДА ГАИЛӘГӘ


Екатеринбургта яшәүче кеше ипотекасыз торак сатып алу ысулын тапкан. Интернетта хатын-кыз белән танышу әкренләп романтик мөнәсәбәтләргә әверелгән. Дөрес, ир-атның финанс ягы авыр булган, ә сөяркәсе аны акча белән мулдан тәэмин иткән. Берничә ел эчендә «ромео» сөйгәненнән 1,5 миллион сум акча алган, аны хатынына фатир сатып алу өчен сарыф иткән. Хәтта ул аннан аерылышмаган да булган. Хәзер алданган сөяркә үзенең акчаларын суд аша кире кайтарырга тырыша.



Александр АЛЁШИН



Вячеслав ШИЛОВ



Максим СМАГИН

ТИШЕК КОПЧӘК

Виталий ВЕСНИН

ҖЕБЕК АШКАЗАН

Бу хәл минем белән автомобиль йөртергә йөрәнү мәктәбендә булды. Теория һәм "площадка" имтиханнарын биргәннән соң, шәһәр буйлап йөрү имтиханын тапшыру бурычы тора иде.

Маршруты шәһәр кырые буйлап уйланган, чөнки анда халык азрак, аулак җирдә җан тыныч, һәлакәт көтелми. Чират буенча мин соңгысы, инде барыбыз да арыган идек. Безнең инструктор имтихан алучы ЮХИДИ хезмәткәренә ашханәгә кереп бераз тамак ялгап алырга киңәш итте. Аның тәкъдименнән баш тарттым – сәбәбе диетада булу. Дөресен әйткәндә, теләсә кайсы җирдә ашап йөрүне бик өнәп бетермим. Алар бит тикшерүче органнардан еракта булу сәбәпле, әллә ни җаваплы сизмиләр үзләрен. Мин машинада көтеп калдым. Әйләнеп килгәч, "гаишник" яңадан җитди хезмәткәргә әйләндә.

– Әйдә, кузгал! – ди миңа.

Мин юлны яхшы беләм, инде инструктор белән берничә мәртәбә узган идек. Имтиханга әләгә торган "куркыныч" урыннары да хәтердә. Шуңа күрә юлымнан ышанычлы барам. Менә сиңа мә, гаишник кинәт:

– Кырыйга чыгып тукта! – диде.

Инструкторның әле бу урында туктарга ярамаганлыгын әйткәне истә – ул җир тар һәм текә аска төшү белән тәмамлана. Имтиханчының "мине ялгыштыру уе" икәнен аңлап, тизлекне киметмичә баруымны дәвам иттем.

– Ишетәсеңме, туктат машинаны! – дип тавышын көчәйтте "гаишник".

– Монда туктарга ярамый! – дип, йөземә каушау чыгармыйча җавап кайтардым.

– Туктат хәзер үк! – дип кычкырды ул яңадан. – Юкса "икеле" чәпим сиңа!

Автомәктәп укытучысы тыныч тавыш белән миңа эндәште:

– Туктат!

Аны тыңларга мәҗбүр булдым. "Авария" сигналын кабыздым. "Гаишник" тиз генә машинадан чыкты да куаклар арасына кереп югалды. Без инструктор белән бер-беребезгә гаҗәпләнеп карашып алдык.

– Менә шулай ул теләсә кайсы юл кырыйларындагы ашханәләрдә туклану! – дип, мыскыллырак сүз әйтеп куйдым.

– Аптырыйм, минем белән барысы да әйбәт, – диде укытучым. – Димәк, аның ашказаны нәзберек...

Озак та үтмәде, бәлагә юлыккан имтиханчыбызның куак арасыннан чыгып килүе күренде. Йөгерүдән мышнап, "җиңеләеп" китүен яшермичә, арткы урынга чумды.

– Имтиханны бирәсең киләме? – дип, көтелмәгән соравын бирергә дә өлгерде.

– Әлбәттә! – дидем мин куркыбрак.

– Шулай булгач, бу турыда ләм-мим, тсс! Аңладыңмы?

– Ничек инде аңламаска!

– Бу хәл сиңа да кагыла! – дип өстәде укытучыма карап. – Киттек!

Бернинди хәвеф-хәтәрсез автодромга да кайтып җиттек. Ә безнең җебек ашказанлыбыз машинадан чыкты да автомәктәп бинасы артына кереп югалды. Күлүдән эчләребез катып бетте.

Экзаменны мин бик яхшы итеп бирдем. Менә шул!

Игорь КИЙКО









ГИППОКРАТ ШАЯРТУЛАРЫ

• Табиб никадәр талантлырак булса, аның янына эләгү шулкадәр кыенрак.

• Безнең медицинабыз белән горурланам. Бер ел инде авырганым юк. Чөнки куркам.

• Медиклар баш табибка шикаять язганнар, ләкин прокуратурада ул гаризаны укый алмаганнар.

• Ярып карау – юлламасыз, чиратсыз һәм ахырда төгәл диагноз куеп үткәрелә торган бердәнбер тикшерү.

• Түләүле табиб сезгә беркайчан да дәвалау физкультурасы билгеләмәс: чөнки ул түләүсез һәм файдасы да тия.

• Пациентка дөрес булмаган диагноз куйганнар, тик дәвалавы да ялгыш булу сәбәпле, ул терелгән.

• • •

Ике таныш очраша.

– Сиңа нәрсә булды?

– Берьюлы ике тешемне суырттым.

– Тукта, син әле бүген иртән генә бер тешем сызлый дигән идең бит. Нигә икене алдырдың?

– Табибның кайтарып бирергә акчасы булмады.

• • •

– Хатыным тавышсыз калды, зинһар ярдәм итегез, – дип мөрәҗәгать итә бер ир табибка.

Табиб киңәш бирә:

– Сез бүген кичен өегезгә соңарып кайтып карагыз... Шуның файдасы тияр дип уйлыйм.

Виктор БОГОРАД



Алсу ГАЙСИНА

Ышан син ирләргә...

Уф, тәнем кыза, башым гүли... Әллә тагын температурам да күтәрелгән инде?.. Әле генә эшеннән кайткан ирем кулын маңгаема куеп карады да смартфонына ябышты.

– Скорый чакыртасыңмы әллә? – дим.

– Юк, алардан файда булмас. Әле шәһәрдәге бөкеләрне ерып чыкканчы... Әле нинди табиблары килә... Ничә сәгатьтән соң... – Ул миңа моңсу гына карап тора башлады.

– Алайса ни эшләргә?.. Сырхауханәгә шалтыратып кара, өйгә врач чакырт...

– Син нәрсә, шуны да аңламыйсыңмы? – дип ачынып куйды ирем. – Безнең табибларга бөтенләй ышаныч юк бит. Дипломнары сатып алынган, уйларында гел акча. Алар сиңа шундый диагнозлар язар, әллә нинди дарулар тәкъдим итәр – ыштансыз калдырырлар! Болай да акчабыз аз!

– Нәрсә, үлеп китсәм дә ярыймы?

– Менә, җүләр. Алар фармацевтлар белән бер мафия!

– Нишләргә соң?

– Хәзер интернеттан берәр файдалы киңәш эзлим әле. Чирнең нинди билгеләре бар, аны ничек дәваларга кирәклеген карыйм.

– Син тапканчы үлеп китәм бугай ахрысы...

– Үлмисең. Исеңдәме минем эшемдәге Руслан? Ничәмә-ничә еллар түләп врачларга йөрде акча әрәм итеп, бер файдасызга. Менә ул үзен интернет файдаланып дәвалады. Укымаган килеш, дипломсыз. Гиппократ анты бирмичә. Хәзер бөтен кешегә киңәшләр бирә, фитнеска йөри, клубларга.

Интернетта эзләнүләр, минем авыру чаткыларыма туры килүен ачыклады – Эбола чире дә, кош гриппы да, диарея да, гомумән, геморройга хәтле. Алардан дәвалану ысулы да шуның хәтле икән. Минем авыруга туры килгәнен тапканчы, кан басымым күтәрелде, йөрәк дуларга тотынды.

– Нигәдер кайсысына тукталырга белмим, – дип борчылгандай әйтте ирем. – Авыр хәлдә икәнсең. Руслан белән киңәшергә кирәк.

Ул бүлмәдән чыкты, минем ишетеп торуымны теләмәде, күрәсең. Ниләр күрәсем бар икән?

– Телефонын алмый, – диде кергәч. Клубында мускулларын ныгыта күрәсең. Көтеп, яңадан шалтыратмыйча булмас.

Миңа тагын да начаррак була башлады, аңымны югалтып каядыр чумдым. Әмма беркадәр вакыттан соң төштәге кебек, сөйләшкән тавыш ишетәм:

– Хафаланырлык сәбәп юк – салкын гына тигән, дисезме? Рецепт бирәм. Таблеткалар капсын, тамагын чайкатсын. Аңа тынычлык кирәк, гел ятып торсын, дисезме?

– Рәхмәт, доктор, – дип, иремнең тавышы ишетелеп калды.

Мин күземне ачтым.

– Ят, торма! – дип әмер бирде ул. – Мин докторны озатыйм...

– Докторнымы? – дигән сүземне көчкә әйтә алдым.

– Әйе, мин "ашыгыч ярдәм" чакырдым. Докторы бик игътибарлы булып чыкты.

– Ә Русланга нәрсә булган?

– Нәрсә булсын, мускул ныгыта...

Шөкер, атна буе телефон аша булмаган "скорый докторы" киңәше белән, үз тырышлыгым белән көчкә терелеп дөньяга кайттым. Менә ышан син ирләргә...

Зиннур ХӨСНИЯР

КАЙСЫГЫЗНЫҢ...

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте.
Кайсыгызның кулы җылы,
Бәйлисе бар йөрәкне...
Х. Туфан

Кайсыгызның бәгъре каткан,
Кемнедер каргыйсы бар...
Телләреңне кискән чакта
Сиптереп агадыр кан.

Кайсыгызның йөзе кара –
Сатасы бар милләтне.
Татарга кирәкмәгәчтен,
Башкага ул кирәкме?!

Туган телнең әллә кайчан
Модасы чыккан инде.
Кайсыгызның баласы бар –
Телен кисәсе иде...

Кайсыгызның кул кычыта –
Баш санын киметергә?..
Гавәмнең җан авазын
Берәрсе ишетерме?!

Күрде башлар күрмәгәнне,
Көрәшергә өйрәтте.
Кайсыгызның кулы дөрес,
Саныйсы бар милләтне?..

Бардак

ШӘМГУН

Нишләсәң дә, нәрсә уйласаң да бардак – бардак инде ул. Бездә, безнең җәмгыятьтә, дөньяда. Кайда, кая карама – атлаган саен...

Менә мигрантлар тулды илгә, менә су баса башлады, менә озакламый тайга яна башлар... Әнә кемнедер талаганнар, банк ставка күтәргән, олигархлар качып беткән – вәт нахаллар, әртисләр чишенешеп, майларына чыдый алмый шәрә тән бер-берсе белән кашына башлаганнар, әнә балалар авырый – акча җыярга кирәк дәваларга, "Крокус Сити", "Зимняя вишня", тегендә шартлый, монда җимерелә, һавада имансыз очкычлар һәм башка, һәм төрле, һәм чамасыз тәртипсезлек.

Бераз якынрак, янәшәбездәге чүп дип санаган хәлләргә килик әле. Көн саен – бер, дөресрәге, 35 нче маршрутта йөри торган автобуска утырып эшкә киләм мин. Дөресен әйтим, гел яман нәрсәләр генә күреп яшәмим, алай уйламагыз. Менә шул автобустагы кондуктор ханымны күзәтәм. Башкаларга охшамаган ул. Тыйнак кына эшли, гади генә киенгән, чәчләрен дә мөселманча җыеп, пөхтә итеп яулык белән бәйләгән. Кулындагы бармагында балдагы да бар. Эшли. Ашыкмый-нитми. Үзбәкстаннан килгән ханым бит инде бу, дип уйлап утырам. Нәрсә, үз илендә ямь таба алмады микәнни? Халык күп инде анда. Эш тә җитеп бетми торгандыр... Бәлки гаиләсендә бер-бер хәл булгандыр?.. Алай дисәң, йөзендә бернинди хәсрәт чаткысы чагылмый. Хәер, кемгә нинди язмыш язгандыр Ходай?! Белә алмыйсың... Барасы җиремә җиткәнче күзәтәм әлеге ханымны. Минем яныма килеп билет та бирде – сдачасы да төгәл. Башкаларга да шулай иплән-җайлап билет кайтара. Мин бит ул яктан килгән кайбер мигрантларның ничек эшләгәннәрен беләм кондуктор булып. Әле менә бер намаз карты бар, ул килә дә колакка иелеп: "Билит надымы?" – дип пышылдый. Алар гына түгел, хәзер үзебезнекеләрнең кайберләре дә шулай итә башладылар. Байыйлар! Пышылдап, күзгә кереп, алдап-ялганлап талыйлар. Нәтиҗәдә, транспорт оешмасы планын тутыра алмый һәм билет бәяләре арта. Менә сиңа мә!

Инде үзебезнең оешмага кердем. Җыештыручы алагаем кәгазь тартмада чүплеккә артык газета-журналларны чыгарып бара. Араларында ниндиләре генә юк!.. Шул исәптән безнеке дә...

Бу хәлләр тормышыбызның алга баруын күрсәтә микән инде?! Мөгаен, юк – бардаклыктыр илдә...

Әнә үсмерләрне 14 яшьтән эшкә урнаштыра башлаячаклар икән... Нәрсә булган? Дөнья бетәме әллә?



Илдар НӘФИЕВ

Евгений ОБУХОВ

Гел файда...

Безнең Галиевичның пенсиясе – йөз мең, күбрәк тә бугай әле! Ничек алай? Менә карагыз.

Кичә, мәсәлән, ул ипигә дип кибеткә керде. Караса, киштәдә бик матур тәлинкәләр тора. Хохлома, гжель һәм шул тәлинкәләрдә күңелне кытыклап кытай сызымнары – өчесе бер итеп, диелгән.

Үзеннән-үзе Галиевичның куллары шунда сузылды – ичмасам, шуларга салып чәй эчсәң дә, торт ашасаң да әйбәт бит инде пенсия акчасына. Алтыны алырга кирәк, әлбәттә. Ну икене, һичшиксез. Бәясенә карады да. Инде акчасын түләп, алган кебек тә булды...

Шуннан соң Галиевич блокнотын алып яза башлады: икене дүрт йөз дә сигезгә тапкырлагач, сигез йөз уналты – болар пенсиядән кулланылмаган акчалар, чын керем!

Һәммәсенә шулай! Менә ысланган балык. Иснәде, кулына алып тотып карады, инде кәрзиненә дә салды... Язып куйды: өч йөз алтмыш җиде... кило ярым апельсиннарны алмады. Чама дигән нәрсәне белә ул. Менә кулинариядә пирожкилар тезелеп тора, алтмышар сумнан берсе – иснәде, пакетны төртеп тишеп, пешкәнме-юкмы икәнен тикшерде – хәтта берсен дә алмады.


Аптекага керде: табиб буыннары авыртканга дару язган иде, кан басымы күтәрелгәнгә һәм салкын тиюгә дә. Хәйран сумма җыела, әһә... Тирән итеп аптека һавасын сулады, ни өчен дисезме, сәламәтлеккә файдасы барлыгын белеп. Үзебездә чыккан аспирин алды – уналты сумнан, әлегә сатуда барлыгын исәптә тотып. Экономия... Менә бит нихәтле керем булды, җәмгысы – ике меңнән артык!

Кичен өстәл артына утырып, көне буена җанга калган акчаларын санады. Барлыгы биш мең ике йөз унике сум! Шуларны пенсиягә кушып карады: 18600. Йөрәге шатлыктан шартлардай булды: бер көнгә никадәр керем!

Аена, шулай итеп, йөз меңнән артып чыга!

Шул куанычтан Галиевич телевизорын кабызды һәм шундук сүндерде дә. Юкка түгел. Блокнотын алып язып куйды: электроэнергия экономиясе өчен биш тиен. Үзегез беләсез, тиеннәр бит пенсионерның бюджетын саклый!

Виктор БОГОРАД



Игорь КИЙКО



Өмет бар...

Йокысыз төн.
Авыр уйлар килеп,
Телеп-телеп ала күңелне:
Бу дөньяда яхшы эз калдырып
Яшәдемме?
Әллә түгелме?
Якыннарым сагынырдай итеп
Изге эшләр кыла алдыммы?
Билгесез бер төмгәк булып әллә
Юл читендә ятып калдыммы?
Яратам, дип кулын сузган чакта,
Кире какмадыммы иркәмне?
Яшьлек юләрлеге белән, кызып китеп,
Кимсетмәдемме мин әнкәмне?..

...Кара төнне яра таң нурлары.
Димәк, алда тагын бер көн бар.
Ашыгырга кирәк!
Гомеремне
Үзгәртергә әле өмет бар...

Ринат АБЗАЛОВ

Ринат АБЗАЛОВ



Рәфкать ИБРАҺИМОВ

Ялган

Ялган ишетеп яшибез,
Ышанабыз ялганга,
Шатланып коллар чабабыз
Безне алдаучыларга.


Кемнәргәдер алдау кирәк
Урыннарын сакларга,
Дөреслекне сөйләмиләр,
Алар мәҗбүр алдарга.

Рекламалар бик шәп кыстый
Ышандырып халыкны,
Бездә бар да яхшы товар,
Үзебез дә данлыклы.

Телефоннар да калышмый
Алдашу өлкәсендә,
Алдау, ялган канга сеңгән
Аларның хезмәтендә.

Көндек инде сайларга да,
Биздек төптән уйларга.
Кушканны сайлау җайлырак
Үзебезне алдарга.

Виталий ПОДВИЦКИЙ





ҖИЗНИ, ТАЛЬЯН һӘМ БЕЗ

Их, хәзерге кебек акылларым булса!.. Нишләр идең дисезме? Юк, әллә ни дә түгел әлеге уфтанып үкенеп куюым. Сүзем тальян гармун турында... Җизнинеке... Ул минем әти ягыннан әбием сеңлесенең ире. Фәхер исемле. Гомер буе тимерче булып эшләде. Осталыгы тирә-якларга мәгълүм һөнәрче. Аның турында бик озак җәелеп китеп сөйләргә мөмкин. Ләкин мин хәзер аның Ватан сугышындагы бер хатирәсен искә төшереп утырам. Гел сөйли иде ул аны мәҗлесләрдә, шул тальянын тартып-сузып уйнап утырганда, бигрәк тә Сабантуйларда туганнар җыелышканда. Дөньябызны онытып тыңлый идек шуның маҗаралы истәлекләрен. Без – балалар өчен, бигрәк тә малайларга шаккаткыч хәлләр бит аның эчтәлегендә. Герой булган икән минем җизни дип уйлап йөри идем. Ничек булмасын, мин бит җизнинең тимерче алачыгында утта кайнап торган тимерләрдән әллә нинди могҗизалы әйберләр ясаганын күргән малай! Ул алачык безнең бакча артында гына иде. Ярдәмчесе – кувалда белән анда-монда тимергә бер тондырып торучысы – Бәдри абзый. Ә җизнинең бәләкәй генә чүкече сандал өстендә биеп тора. Аларның шулай эшләвендә ниндидер музыка чыгып яңгырый сыман.

Җизнинең төшке ашкамы яки кичке якта эштән кайтканда безгә кереп чыга торган гадәте бар. Минем гармунда уйнаганымны тыңлый. Мактап куйгалый. Әти-әнигә дә: "Малаегыз бик сәләтле!" – ди. Шулайдырмы, юктырмы, мин анысын белмим, әмма мактаулы сүзләр тыңлавы рәхәт. Ул үзе дә бит әлеге дә баягы тальянын бик шәп сайрата. Кыңгырауларын чыңлатып җибәрсә, әллә нинди сихри дөньяга чумасың.

Үзе сөйләве буенча, аны сугыштан алып кайткан икән. Җиз телле дип тә өсти.

Бабам белән бераз "шайтан суы" төчкертеп алган булсалар, әллә ниләр сөйләп китәләр. Бабай – үзенекен, җизни – үзенекен. Бабай Волхов фронтыннан пленга эләккән. Ә җизни машина йөртүче булып сугышкан. Кулында – автомат һәм руль. Ә бабай – миномётчик.

Җизнинең машинасы тупка тотылып, тәгәрмәчләре эштән чыга һәм радиаторының суы агып бетә. Җизни үзе болай сөйли: "Кулга ядрә кыйпылчыгы тиеп нишләргә белмичә торганда, якындагы окоптан берничә безнең солдат чыгып, урманга таба йөгерделәр, ә миңа инде алар артыннан иярергә соң. Арттан аларга ут ачып, немецләр килә. Ә мин мотор капкачын ачтым да, кысылып, әле суынып та җитмәгән моторны кочакладым. Кайнар, нәгъләт, шулай да тән пешәрлек түгел. Капкачны эчке яктан ачылмаслык итеп каптырып куйдым. Немецләр килделәр, сизәм, машинаны бер кат әйләнеп чыктылар, эт кебегрәк һау-һау сөйләштеләр дә безнекеләр артыннан эзәрләкләп китеп бардылар. Тынымны да чыгармыйча байтак яттым. Инде караңгы төшеп килә, эчкәрәк этеп куелган автоматымны алып капкачны ачтым. Янәшәдә шикләнерлек тавышлар ишетелми, кабинаның пыяласы коелып, идәндә аунап яткан тальянны каплаган. Күрәсең, немецләр аңа игътибар итмәгәннәр, бәлки, итеп тә кирәксенмәгәннәрдер. Ник дисәң, эшләре тыгыз".

Менә шуннан соң җизни, яраланган килеш, гармунны да ташламыйча, безнекеләрне табып, дәваланып сугыштан кайткан. Гомере буе шул гармуныннан "Герман" көен уйнап йөрде, мине дә җырлаткалый иде. Хәзер дә ул җырны җырлап, сугыштан кайта алмаганнарны искә төшерәм. Сугыш куптаручыларга ләгънәт итеп... Тик менә җизнинең генә тальянын саклап кала алмадым – каядыр югалды. Якты дөньядан хуҗасы китү хәсрәтеннән ул да мәңгелеккә тынгандыр инде...

Алмаз ХӘМЗИН



Хәтер өчен җөй.

Борис СТАРЧИКОВ, 1965 ел.



– Мондый дата юк иде!

Эрнст ГЕЛЬМС, 1966 ел.



• • •

Катарда нефть һәм газ ятмалары тапкач, бер бедуин 35 ел эчендә илендәге халыкны дөньяда иң бай иткән. Бездә күптәннән нефть, газ, алтын, платина, алмазлар һәм бөтен Менделеев таблицасындагы казылма байлыкларның булуын ачыклагач... бер фикергә киләләр – илдә бедуиннар юк икән бит.

• • •

Бер гүзәл зат барлык ирләрне сарык дип атаган, алар бары тик тиешле болында гына көтүләмиләр икән.

• • •

Университет ректоры, физфак деканы китергән сметаны карагач, ухылдап, болай дигән:

– Нигә бу физиклар һәрвакыт кыйммәтле җиһазлар, приборлар таләп итәләр? Менә, мәсәлән, математиклар акча белән кәгазь, карандаш һәм ластиклар. Бераз уйланып торгач, ә философлар, гомумән, тагын да әйбәтрәк... Аларга ластиклар да кирәкми икән.

• • •

Хәзер кешеләрне пенсиягә ничек яшәргә дигән сорау түгел, ә ныграк аңа хәтле ничек чыдарга, дигән борчу бимазалый.

• • •

Ике сәрхуш кибеттә.
– Кара, коньяк өч мең сум тора!
– Эчмәүчеләр өчендер ул.

• • •

– Ачыгыз, полиция!
– Ә нигә анда бикләндегез?

• • •

Әгәр дә гастроэнтеролог, кардиолог, невролог, эндокринолог һәм уролог тәкъдим иткән ашамлыкларны менюдан алып ташласаң, миңа гел су гына эчеп торырга туры киләчәк, анысы да әле кайнаган булырга тиеш.

• • •

Хатын-кыз – ул прокуратура кебек: башта эләктерә, аннан котырта, алга таба ирегеңнән дә мәхрүм итәргә мөмкин.

• • •

– Телевидение белән мавыгу аркасында күбрәк укый башладым.
– Шаярып әйтәсезме?
– Юк, чынлап та шулай. Анда җыен юк-бар әйбер күрсәтәләр – карыйсы да килми хәтта.

Вячеслав ШИЛОВ



Александр ШУЛЬПИНОВ





КЕМГӘ НӘРСӘ...

Хөрмәтле редакция! Мунчаның файдасы һәммәбезгә мәгълүм: "Сәламәт тәндә – сәламәт акыл!" – диләр халыкта. Ләкин безнең очракта түгелдер... Йортыбызның тәрәзәләре каршында сауна дип атала торган мунча төзеделәр, ресто-раны-ние белән бергә. Хәзер инде күңелле шау-гөр кичәләре белән генә мавыкмыйбыз, ә тәмле-томлы кулинария төтеннәре иснәп рәхәтләнәбез. Мунчасы газ белән ягыла, ә менә ресторан кухнясы ризыкларын утын яндырып әзерлиләр. Төтен, пар белән кушылып, безнең күпкатлы йортыбызны тәүлек буе томалап тора. Ачык форточкалардан бүлмәләргә корым, сөрем куна. Төннәрен йоклап та булмый.

Әле мунча хуҗасы белән ресторан кил-мешәкләренең планнары зурдан икән – шул тирәдә ниндидер алагаем комплекс төзү. Безнең турында уйлаучы да юк. Менә шундый нәрсә килеп чыга: кемгәдер юыну, күңел ачу – шатлык, ә безгә себерке яфрагы – хур урыныбызны каплау өчен генә.

КАЗАН **Фучик урамы, 64 нче йортта яшәүчеләр.**

МЕНӘ СИҢА, МӘ!..

Кадерле "Чаян"!

Быелгы ел Гаилә елы дип игълан ителгән, димәк, балалар, әти-әниләр һәм тәрбия мәсьәләләре – иң элек... Әмма тора-бара бөтен нәрсә үзгәрә. Мәсәлән, Совет районының "Беседа" торак комплексындагы "Кактус" балалар үзәге эш юнәлешләре. Моның шулайга әйләнүе чираттагы алкомаркетның барлыкка килүенә бәйле. Сорау туа торгандыр: "Кактус кайда да һәм кереп-чыгып, кәеф-сафа кору урыны кайда?

Эш шунда: балалар үзәге – балалар бакчасы булмауга алмаш, торак йортының беренче этажын арендага тота. Хәзер "Кактус"та мәктәпкә хәтле 50 бала шөгыльләнә. Менә шул бинаның күршесенә алкомаркет килеп урнашты. Закон буенча, алай булырга тиеш түгел. Бу мәйданда эшләүче балалар үзәге хуҗалар өчен файдасыз, шуңа күрә ул аренданы озынайту турында уйламый. Уйлап карагыз: Гаилә елында бу!

Элек шундый лозунг бар иде "Иң яхшысы – балаларга!" Хәзер исә бөтен барысы да киресенчәмени?.. Барысы да – алкобизнеска һәм туя белмәс аның хуҗаларына.

Тәрбия үзәгенең әти-әниләре.

КАЗАН





Госман Мохтасар улы ЗӘЙНЕТДИНЕВ (тәхәллүсе – Госман Садә) – татар шагыйре, журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1994 елдан), Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (1988 елдан).

Ул 1949 елның 23 февралендә Башкортстанның Аскын районы Әмир авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң берникадәр вакыт Аскын һәм Караидел район газеталарында тәрҗемәче һәм әдәби хезмәткәр булып эшли. 1967–1972 елларда ул Уфада Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Студент елларында җитди рәвештә әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый.

Университетны тәмамлаганнан соң Госман Садә Казанга күчеп килә. 1972–1979 елларда «Коммунист Татарии» («Татарстан коммунисты») журналында тәрҗемәче, ә 1979 елның февраленнән «Яшь ленинчы» газетасы редакциясенә әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли. Бу газетада шактый еллар эшләгәннән соң аның журналистлык хезмәте республиканың «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Мәгърифәт» газеталарында дәвам итә.

Госман Садә басмада дөнья күргән өч шигъри китап авторы: «Мәхәббәт елы» (1985), «Җиләкле тәрәзәләр» (1987) һәм «Тайфун күзе» (1990). Нигездә, ул – лирик шагыйрь. Тормышчан шигъри детальләр, халыкчан образы, йөгерек тел, фикер-хисдә ихласлык, шигырьне композицион яктан матур һәм җиңел аңлаешлы итеп төзү осталыгы – болар шагыйрь иҗатының үзенчәлеген тәшкил итәләр. Ул шулай ук композиторлар тарафыннан көйгә салынган һәм халык арасында популярлык казанган милли рухлы «Әссәламегаләйкем», «Рамазан», «Җомга азаны» кебек җыр текстлары авторы буларак та билгеле.

2014 елның 14 гыйнварында 65 нче яшендә Госман Садәнең йөрәге тибүдән туктый.

ӘССӘЛАМЕГАЛӘЙКЕМ!

Резеда Ахиярова көе

Таң ата да кояш чыга,
Кояшны сәламли көн.
– Саумы, Кояш, сүнмәс учак!
Әссәламегаләйкем!

Тел ачкычы, иман биргән
Сөекле туган телем!
Үз телемдә сиңа сәлам,
Әссәламегаләйкем!

Әй игенче, күкрәп үссен
Кырларда синең иген.
Икмәк тотып сәлам юллыйм,
Әссәламегаләйкем!

Ачыйк бәхет ишекләрен,
Бәхетле булсын һәркем.
Әй кардәшләр, милләттәшләр,
Әссәламәгаләйкем!

Таң ата да кояш чыга,
Кояшлы бездә һәр көн.
Кояш белән сәлам юллыйм,
Әссәламегаләйкем!

СИН БИТ ШАГЫЙРЬ ХАТЫНЫ

Бергә булсаң сизелми дә
Кышның зәһәр салкыны.
Кышларны да җылытасың,
Син бит шагыйрь хатыны.

Син булганда озак сүнмәс
Сүзләремнең ялкыны.
Учакка да җан өрәсең,
Син бит шагыйрь хатыны.

Шәм шикелле балкып тора
Хисләремнең алтыны.
Эчем тулы энҗе күргән
Син бит шагыйрь хатыны.

Ярты сүздән аңлый алу –
Шул яшәүнең шартымы?
Гомеремнең ярты шарты –
Син бит шагыйрь хатыны.

Гөлтләп янган утка охшаш
Йөрәкләрнең тартымы:
Курку белмәс кушйөрәкле –
Син бит шагыйрь хатыны.

Җырлап аккан чишмәгә тиң
Гомеркәйләр агымы...
Шул агымда, гел янымда –
Син бит шагыйрь хатыны!

САНДУГАЧ

Мөлдерәмә нурлы таң тугач,
Чык тамчысы гөлгә сарылгач,
Сайрамасын ничек сандугач! –
Күңеле тулы ялкын, моң булгач.

Җыры оча иңләп тугайны,
Җыр канаты – алтын буяулы.
Моңнан гына торган шул таңны
Кинәт кызым елап уянды.

«Ник елыйсың болай, чү, кызым?!
Йом күзеңне, йокла, йолдызым.
Сайрасын ла, кызым, сандугач,
Җырны шулай өзелеп сагынгач».

Бишегенә кулым кагылгач,
Пышылдады кызым: «Сан-ду-гач!»
Сабый тынды, елау басылды, –
«Сандугач» дип теле ачылды.

АК ӘБИЛӘР

Бер күрешү бер гомер дип
Дога кыла ак әбиләр.
Яңа төсмер мәгънә ала
Борынгы җыр, иске көйләр.

Ходайның һәр биргән көнен
Дога кылып сәламлиләр.
Ил шатлыгы, ил аклыгы –
Ак яулыклы ак әбиләр.

Ак әбиләр бер елмайса,
Үсә күңел офыклары.
Яннарында уйнап йөри
Орчык буе оныклары.

Ходайның һәр биргән көнен
Дога кылып сәламлиләр.
Ил шатлыгы, ил аклыгы –
Ак яулыклы ак әбиләр.

Мич янында тып-тын гына
Тыңлап тора киленнәре.
Шулдыр үзе – өйгә иман,
Татулыкның иңүләре!..

Ходайның һәр биргән көнен
Дога кылып сәламлиләр.
Ил шатлыгы, ил аклыгы –
Ак яулыклы ак әбиләр.

Фарсель ЗЫЯТДИНОВ

БАТУЛЛАДА КУНАКТА

Бервакыт Мәскәү Әдәбият институтының тулай торагында булырга туры килде. Дөресрәге, Батулла янына кердем. Батулла ул чакта студент... шул институтта укый иде.

Әйтергә кирәк, бик җылы каршы алды Батулла. Әле дә онытa алмыйм. Аның бүлмәсенә керүгә, иң элек стенадагы зур картага күзем төште. Анда Себер киңлекләреннән алып Мәскәү тирәсенә кадәр Татар җирләре җәйрәп ята иде... Бик күп калалар... елгалар – барысы да тәүге исемнәре белән төркичә язылган... Әнә Итил елгасы агып ята... Нократ...

Манты әзер булгач, Батулла берара югалып торды һәм әйләнеп тә керде. Үзе генә түгел күрше бүлмәдән ике кызны да әләктергән: берсе – маҗар, икенчесе болгар кызы... Кыскасы, Батулла әйтмешли, безнең кан кардәшләр. Күреп торам: ничек тә минем күңелне күрмәкче Батулла.

– Мәҗлес саф татарча булачак, – диде ул һәм шунда ук бүлмәнең нәкъ урта бер җиренә – идәнгә – бик матур келәм җәеп куйды. – Ә хәзер инде утырышыйк... алай түгел, менә болай итеп – аякларны бөкләп... Кызлар, аякларны бөкләп, дим.

Аягын бөкли алмаган маҗар кызына Батулла үзе булышты... Хәйран шәп килеп чыкты бу... Болай да кыска итәкләр, аякларны бөкләп куйгач, инде үз вазыйфаларын үтәми иделәр бигрәк тә мантыга үрелгәндә...

Шулай бераз утыргач һәм Казан кунагы алып килгән кучтәнәчтән авыз иткәч, Батулла электроорганда уйнап, үзе җырларга кереште:

Кызлары да кызлары,
Күзләр генә кызмалы...
Бу кызларны үстергәндер
Болгар, Маҗар илләре.
Бигрәк матур үзләре.
Үзләреннән матур кебек
Күренеп торган җирләре.

Кәли-кымма, кым-мая,
Зәкәрия кым-мая.
Аяклары сиңа, Фарсель,
Калган җирләре мая.

Батулла җырлаудан туктагач, кызлар шаулатып кул чаптылар.

Кызлар кул чаба, Батулла рәхәтләнеп көлә. Кунак та көлә, кызлар кул чаба... Барыбыз да көләбез...

Шул гүзәл мизгел әле дә колагымда чыңлап тора...





• • •

Таныштыру агентлыгында бер хатын булачык ирендә күрергә теләгән сыйфатларны тезеп чыга:

– Ул акыллы, интереслары күпьяклы, хайваннарны ярата торган, миңа һәрвакыт мавыктыргыч хәлләр турында сөйләүче, дөнья хәлләрен белеп торучы, мине бервакытта да бүлдермәүче булырга тиеш.

– Болай булгач сезгә ир түгел, ә телевизор кирәк булачак...



ЧАЯН
САТИРА һәМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 5 (1942) май 2024

Баш редактор: Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
420047, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.05.2024 ел.
Тираж – 2120 Заказ А-0923
Редакциянең адресы: 420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле
16+

Уйна да, уйла да!

ЖЫРЧЫ ЗӨФӘР . . .
ЯЗ ЧӘЧӘГЕ
КОМПОЗИТОР ФАСИЛ . . .
МЕЖА
15
ГЕРМАНИЯДӘ ТАШКҮМЕР БАССЕЙНЫ
ЯЗГЫ ЧӘЧҮ ТЕХНИКАСЫ
"ТӘРӘЗ САЕН . . . ГӨЛ ҮСӘ"
1
13
ЧӘЧӘКНЕҢ ТӨП СЫЙФАТЫ
КОМПОЗИТОР ХӘСНУЛ . . .
"ИРКӘМ, . . . ИНДЕ"
6
"СИРЕНЬНӘР ХУШ ИСЛӘР . . ."
. . .-МӘЗ
КУХНЯДА ДА, ТӨЗЕЛЕШТӘ ДӘ
ТНВда ТАПШЫРУ (-4)
ЯКТЫ, НУРЛЫ (ФАРСЫЧА)
ГАРМУНЧЫ . . . ТУИШЕВ
СУРӘТНЕҢ АРТКЫ ӨЛЕШЕ
14
ТАЛЧЫГУ
КОМБАЙН
СОВЕТ ТАНКЫ ". . . ВОРОШИЛОВ"
"БӨДРӘ . . ."
12
3
"ЙОСЫФ . . . ЗӨЛӘЙХА"
БАСУ
ШАГЫЙРЬ ШӘРИФ . . .
16
ХӘРБИ МАШИНА
АТА-. . .
"АНДА . . . СУЛАРНЫҢ ГӨМЕРЕМНЕҢ ЭЗЕННӘН АККАНЫ"
10
ДУС-. . .
ШАТЛЫК (-2)
7
"ГАКЫЛГА НУР БИРГӘН . . ."
АНТОНОВ САМОЛЕТЫ
"ОЗАТА . . ."
ТУГАН . . .
СЫЕР АВАЗЫ
СӘНГАТЬ ТӨРЕ
. . . НУРИ
ТАРТТЫРГАН ЯРМА
8
2
"КҮМЕЛГӘЧ ГӨЛГӘ . . ."
". . . ЧӘЧӘК АТА ИЛЕМ"
ТЫНЛЫ ИНСТРУМЕНТ (-4)
АТМОСФЕРА КҮРЕНЕШЕ
4
«БАЛА» ИСКЕЧӘ
"ЯКЫН ДУСТЫҢ БАРЫН . . ."
5
9
11

Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Дуслар кемнәр алар?

2. Нәрсә ул тибу?

3. Дүшәмбе нәрсәдән башлана?

4. Тормыш кая тәгәри?

5. Әгәр дөнья белән хатын-кыз җитәкчелек итсә, ни өчен сугыш беркайчан да булмас иде?

6. Нигә сум түбән тәгәри?

7. Иртә кайчан чынчынлап хәерле?

ҖАВАПЛАР

1. Аларны бик яхшы белүебезгә карамастан, яратабыз да әле. 2. Шул ук башарты, ләкин беркадәр астарак. 3. Зарлану моментыннан. 4. Кайдан килеп чыккан, шунда кабат тәгәри. 5. Чөнки сугыш алып бару өчен стратегия белән логика кирәк. 6. Тиеннәрне әйләнештән чыгардылар, шуңа күрә сумны саклау чыганагы югалды. 7. Сәгать 11 тулган чак, календарьда – җәй, ә алда – отпуск.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 4 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«БИК ЕРАКТА ИДЕК БЕЗ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Р. ШАКИРОВА (Сарман р-ны, Әлмәт ав.),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).

Җиңүчебез – Казаннан **Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ!**

Салават НИГЪМӘТЕВ



Безнең сәяси карикатура күргәзмәсе күп кенә яңа исемнәр ачты, аларның берсе – бүген тәкъдим ителгән вернисажның авторы Салават Нигъмәтев. Салават борынгы Бохара каласында дөньяга килгән. 1905 ел истәлеге исемендәге Мәскәү сәнгать академиясе училищесын тәмамлагач, комсомол путёвкасы буенча Чаллы шәһәренә килгән. Анда озак еллар буе Архитектура идарәсендә проектчы-рәссам булып эшләгән. Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы. Бүген ул бай тарихлы Казан каласында яши.

